ГЛАВА СОБОЛЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Береговая, д.30, с. Соболевское, 422595

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ СОБОЛЕВСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яр ур., 30 нчы йорт, Соболевский авылы, 422595

Тел.: (84379) 35-7-22, факс: (84379) 35-7-22.

__________________№________________

На №______________от________________

## КАРАР
## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү 22.11.2013 ел № 90 тәртибенең 2 пункты (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә) нигезендә, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы?- ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Карамышиха авылындагы зират территориясен төзекләндерү), дигән сорау буенча 2024 елның 12 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмәгә ярашлы, сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 30 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 20 граждан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
- «Әйе» позициясе өчен җыенның 20 катнашучысы тавыш бирде.
- «Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы?:

- ремонт, коймалар төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Карамышиха авылындагы зират территориясен төзекләндерү) дигән мәсьәлә буенча карарны таныргa.

3. Югары Ослан муниципаль районының Соболевский авыл җирлегенең Карамышиха авылында гражданнар җыенының нәтиҗәләрен Соболевский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Соболевский авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: _____________ О.Н.Майорова